**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Нәби Дәүлинең «Бәхет кайда була?» шигыре**

**1. Нәби Дәүли язучының псевдонимы. Аның тулы исеме-фамилиясе ничек?**

**а) Нәбиев Дәүли;**

**ә) Нәби Дәүлиев;**

**б) Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин.**

**2. Ул кайда туган?**

**а) Әлки районы Мәүләшә авылында;**

**ә) Казан шәһәрендә;**

**б) Арча районы Гебердәк авылында.**

**3. Әдип нинди тормыш авырлыклары белән очраша?**

**а) бик ярлы гаиләдә бабасы белән генә яши;**

**ә) күп балалы гаиләдә әнисе белән яши;**

**б) дүрт яшендә — әтисе, бераздан әнисе дә үлеп, балалар йортында үсә.**

**4. Бөек Ватан сугышы елларында ул кайда була?**

**а) сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә;**

**ә) әсирлеккә эләгеп үлә;**

**б) сугыштан качып кайта.**

**5. Сугыш турында нинди күләмле әсәрләре бар?**

**а) «Яшәү белән үлем арасында», «Бәхет кайда була?»;**

**ә) «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион»;**

**б) «Яшәү белән үлем арасында».**

**6. Бәхетнең кайда булуын малайларга кем әйтә?**

**а) үзләре белә;**

**ә) алмагач әйтә;**

**б) бабай әйтә.**

**7. «Бәхет кайда була?» шигыренең төп геройлары кем?**

**а) Галимҗан, Илдус;**

**ә) Ирек, Самат;**

**б) Галимҗан, Самат.**

**8. Малайлар нинди нәтиҗә ясый?**

**а) Бәхет була хезмәттә!**

**ә) Эшләмәсәң, тагын да рәхәтрәк!**

**б) Уенга бернәрсә дә җитми!**

**9. Бәхетнең хезмәттә икәнлеген күрсәткән әсәр кайсы?**

**а) «Чыбыркы»;**

**ә) «Бәхет кайда була?»;**

**б) «Бөтенесе кирәк».**

**Ачкыч**

1. Б
2. А
3. Б
4. А
5. Ә
6. Б
7. А
8. А
9. Ә

# Бәяләү

**8-9 балл – “5”ле**

**6-7 балл – “4”ле**

**4-5 балл – “3”ле**